**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары**
**2017-2018 уку елы. 10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты - 180 минут**
**максималь балл - 76**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге ирен ассимиляциясе чагылыш тапкан сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Роксана – бик сөйкемле, көнбагыш чәчәге кебек сап-сары бөдрә чәчле, томырылып торган зәңгәр күзле кыз.* (Р.Хафизова)

**а) көнбагыш;**
ә) сөйкемле, томырылып;
б) Роксана, сөйкемле, көнбагыш, бөдрә, томырылып, торган;
в) Роксана.

2. Җөмләдәге тел арты (кече тел) ассимиляциясе чагылыш тапкан сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Гарәп язуы борынгы болгар дәүләтенә зур халыкара мәйданга чыгу мөмкинлеген җиңеләйткән, үсешендә бик мөһим этәргеч булган.* (Р.Кадыйров)

а) гарәп;
ә) гарәп, борынгы, мәйданга;
**б) борынгы, мәйданга;**
в) җиңеләйткән.

3. Шигырьдәге сүз басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,*
*Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер,*
*Катыштырма вәләкин телгә телне.* (Дәрдемәнд)

а) кил, бер, туган, башка, телне, бүтән, телләр, белү, яхшы, телгә, телне;
**ә) туган, башка, телне, бүтән, телләр, белү, яхшы, телгә, телне;**
б) өйрән, һөнәрдер, катыштырма, вәләкин;
в) туган, башка, телне, бүтән, телләр, белү, яхшы, катыштырма, телгә, телне.

4. Архаизм булган ***талиб*** сүзенең хәзерге көндә кулланыла торган варианты дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) табиб;
ә) укытучы;
б) сәяхәтче;
**в) студент.**

5. Җөмләдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Кышның салкын сулышын кош-кортлар, җәнлекләр бик тиз сизделәр, аларның тавышы бик сирәк ишетелә: күбесе язга кадәр йокыга талган.* (Вакытлы матбугаттан)

а) кош-кортлар;

**ә) сулышын, кош-кортлар;**

б) сулышын, кош-кортлар, җәнлекләр;

в) сулышын, кош-кортлар, күбесе.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзгә морфологик анализ дөрес ясалган рәтне билгеләгез. (2 балл)

Усак яфраклары, үзара **серләшкәндәй**, әкрен генә җилфердәшәләр. (Л.Ихсанова)

а) саф рәвеш, ясалма, төп дәрәҗәдә, *җилфердәшәләр* фигыленә ияргән;

ә) үткән заман хикәя фигыль, ясалма, зат-сан белән төрләнмәгән, барлыкта, *җилфердәшәләр* фигыленә ияргән;

б) үткән заман сыйфат фигыль, ясалма, барлыкта;

**в) охшату-чагыштыру рәвеше, ясалма, төп дәрәҗәдә, *җилфердәшәләр* фигыленә ияргән.**

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Менә ни өчен дөнья бердән яктырып **та**, чистарып **та** киткән икән!* (Ә.Еники)

а) урын-вакыт килеше кушымчасы;

**ә) җыючы теркәгеч;**

б) көчәйтү кисәкчәсе;

в) бәйлек.

8. Җөмләдәге хәбәрләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Урамнар пычрак, чокыр-чакырларда су, өйләр, коймалар гел юеш.* (Ә.Еники)

**а) пычрак, юеш;**

ә) пычрак, су, юеш;

б) пычрак, чокыр-чакырларда, юеш;

в) юеш.

9. Җөмләгә дөрес билгеләмә бирелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Җәй көннәрендә аңа нинди генә кошлар кунмады да ничек кенә сайрамады!* (Н.Дәүли)

**а) раслау, тойгылы хикәя, җәенке, ике составлы, тулы;**

ә) инкяр, тойгылы хикәя, җәенке, ике составлы, тулы;

б) инкяр, хикәя, җәенке, ике составлы, тулы;

в) раслау, боерык, җәенке, ике составлы, тулы.

10. Бер составлы фигыль җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Тәвәккәллек белән батырлык бер чишмәдән чыгар. (Мәкаль)

ә) Акыллы кеше өйрәнер, ахмак өйрәтер. (Мәкаль)

**б) Игелек эшен озакка сузарга ярамый. (Мәкаль)**

в) Наилнең укулары ничек бара? (Ф.Хөсни)

11. Иярчен җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Иртәңне ничек башласаң, көнең шулай узар.* (Мәкаль)

**а) аналитик иярчен рәвеш җөмлә;**

ә) синтетик иярчен рәвеш җөмлә;

б) аналитик иярчен вакыт җөмлә;

в) синтетик иярчен шарт җөмлә.

12. Кушма җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Ул баскан эзләрне кар күмгән, ул йөргән урамнар тарайган сыман иде.* (Н.Гыйматдинова)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

ә) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

б) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә;

**в) катнаш кушма җөмлә.**

## II. Башыгызны эшләтегез.

Төрле илдә этләр ничек өрә икән? (8 балл)

Татарларда – “...-...” һау-һау

Урысларда – “...-...” гав-гав

Алманнарда – “...-...” вау-вау

Инглизләрдә – “...-...” ба-ба

Французларда – “...-...” ау-ау

Итальяннарда – “...-...” бу-бу

Төрекләрдә – “...-...” һов-һов

Японнарда – “...-...” кьян-кьян

## III.Теоретик бирем.

Киләчәк заман хикәя фигыль турында белгәннәрегезне язгыз.

Киләчәк заман хикәя фигыльләрнең дөрес язылышына караган кагыйдәләрне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. (10 балл)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Алтын кирәкми, акыл кирәк: акыл булса, алтын табыла*. (Мәкаль)

1. *Акыл* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (4 балл)

2. *Акыл* тамырыннан яңа сүзләр ясагыз. Аларның кайсы сүз төркеменә караганлыкларын күрсәтегез. (6 балл)

3. *Кирәк*, *булса, табыла* сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (6 балл)

4. Җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. (8 балл)

5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (10 балл)

Текст язуга таләпләр:
- текст төзелеше ( башлам, төп өлеш, йомгаклау);
- җөмләләр дөрес, төзек булырга тиеш;
- язма телнең  бай, сурәтле булуына  игътибар итәргә;
- орфографик грамоталылыкка игътибарлы булырга.